СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ИЖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

*26 МАРТ, 1997ел.*
*ЧӘРШӘМБЕ*

*Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга.* | *№ 33 (8045)* | *Бәясе билгеләнгәнчә.*

## 30 март - Татарстан Дәүләт Советына депутат сайлау көне

## ҮЗАРА АҢЛАШУ БЕЛӘН

Дүшәмбе көнне хуҗалыкара төзелеш оешмасы клубына 50 нче номерлы Октябрь административ территориаль сайлау округыннан Татарстан Дәүләт Советына депутатлыкка кандидат, район хакимияте башлыгы Фатих Сәүбән улы Сибагатуллин белән очрашуга төзүчеләр, шикәр заводы эшчеләре, поселокта яшәүче пенсионерлар җыелдылар. Кандидатның ышанычлысы З.А.Шабаевның кыскача таныштыру чыгышыннан соң халык каршына Фатих Сәүбәнович үзе чыкты. Сайлаучылар белән кыска, әмма конкрет, эшлекле бу аралашу кандидатның югары дәүләт властенда халык мәнфәгатен нык якларлык белеме, энергиясе, тәҗрибәсе һәм иң мөһиме - омтылышы барлыгын ачык чагылдырды. Иптәш Сибагатуллин үзен депутатлыкка кандидат итеп күрсәткән «Норлат шикәр заводы» акционерлык җәмгыяте коллективына рәхмәт белдереп, хакимият башлыгы буларак та, депутатлыкка кандидат буларак та башкарасы эшләренең кыскача программасын бәян итте. Иң беренче итеп шәһәрне су, газ белән тәэмин итү, шикәр заводын ел әйләнәсенә эшләтү, аны реконструкцияләү юнәлешендәге ниятләре белән бүлеште. Авылларны реформалаштыруга кагылып, заводның «Восход» ярдәмче хуҗалыгында башлаган киң колачлы эшчәнлеген, беренче уңышларын уңай яктан телгә алды. Хуҗалыкара төзелеш оешмасы коллективы хезмәтенә югары бәя биреп, киләчәктә аларны эш һәм хезмәт хакы белән тәэмин итү көн тәртибеннән төшмәячәген белдерде. Фатих Сәүбәнович районның потенциаль мөмкинлекләре зур булуын ассызыклап, күп тармакта планлаштырылган эшләрне санап үтте. Авылны үстерү, шәхси хуҗалыкларны киңәйтү, эшкәртү промышленностенда эшләрне җайга салу кебек темаларга да кагылды.

Сайлаучылар кандидатка үз сорауларын да бирделәр. Аларның күбесе җирле службалар хезмәтенә кагылганлыктан, Фатих Сәүбәнович 15 апрельгә кадәр бу микрорайонда «Ачык хат көне» үткәреләчәген искәртте, сөйләшүне шунда дәвам итәргә тәкъдим итте, үзеннән торганнарны һичшиксез хәл итәргә вәгъдә бирде.

Соңыннан депутатлыкка кандидат белән очрашуда катнашучылар барлык сайлаучыларга мөрәҗәгать белән чыктылар. (Ул бүген газетада игълан ителә). Очрашудагы рухи күтәренкелек, үзара аңлашулы атмосфера сайлаучыларның үз кандидатларына тирән ышаныч күрсәтергә бик теләп әзер булуларын күрсәтә иде.

**С.ХӘЙРУЛЛИНА.**

**50 нче Октябрь административ - территориаль сайлау округыннан Татарстан Республикасы Дәүләт Советына депутатлыкка кандидат Ф.С.Сибагатуллин белән очрашуда катнашучыларның сайлаучыларга**

## мөрәҗәгате

Хөрмәтле сайлаучылар!

1997 елның 30 мартында Татарстан Республикасы Дәүләт Советына депутат сайлау була. Дәүләт властеның югары органында Октябрь районының күпмилләтле халкы депутаты булып алга карап эш итүче, грамоталы, халык мәнфәгатьләрен якларга сәләтле кеше торырга тиеш.

«Норлат шикәр заводы» АҖ коллективы Татарстан Республикасы халык депутатлыгына кандидат итеп Фатих Сәүбән улы Сибагатуллинны күрсәтте.

Югары профессиональлек, бай тормыш тәҗрибәсе, кабул иткән карарларын үтәүдә ныклык, хезмәт кешесенең психологиясен, аның ихтыяҗларын, өмет һәм омтылышларын якыннан белү - депутатлыкка кандидатны кыскача гына характерлый торган сыйфатлар шулар.

Фатих Сәүбән улы килгәннән соң районадагы икътисадый үзгәрешләр барыбызның да күз алдында. Болар авыл хуҗалыгы предприятиеләрен, колхозларны һәм совхозларны реформалау да, 5 ел тукталып торганнан соң Каравыл Тавы янында Чирмешән елгасы аркылы күпер төзеп файдалануга тапшыру эшләрен яңарту да, берничә торак пунктны табигый газ челтәренә тоташтыру да, шәһәрара аэропорт, Илья чиркәве төзү дә, «Агрохимсервис» АҖнең матди - техник базасын ныгытып, хуҗалыкларга зур күләмдә минераль ашламалар кайтару да, бюджет сферасында эшләүчеләргә хезмәт хакын, пенсионерларга тиешле пенсия һәм пособиеләрне вакытында биреп бару да, районда хокук тәртибен ныгыту да.

Без, очрашуда катнашучылар, «Норлат шикәр заводы» АҖ хезмәтчәннәре, барлык сайлаучыларга 1997 елның 30 мартында тирәнтен уйланган һәм баръяклап үлчәнгән карар белән сайлау участогына килеп, халык депутатларының район Советы рәисе, район хакимияте башлыгы Фатих Сәүбән улы Сибагатуллинны яклап тавыш бирергә чакырып мөрәҗәгать итәбез.

## Безне дә кайгырта ул

Илья чиркәве Советы исеменнән без христианнар турында зур кайгыртучанлык күрсәткән өчен Ф.С.Сибагатуллинга чиксез рәхмәтебезне газета аша җиткерәсебез килә. Чиркәү төзелеше 1996 елда тукталган һәм ул эшнең дәвам иттереләчәгенә бер өмет тә калмаган иде. Әмма хакимияткә яңа башлык килгәч эш җанланды. Санаулы айлар эчендә шәһәрдә гүзәл гыйбадәт йорты калкып чыкты. Һәм безне районда христиан динендәгеләргә дә, мөселманнарга да бердәй мөнәсәбәт булуы куандыра. Меңнәрчә диндәшләребез исеменнән Фатих Сәүбәновичка реформалар уздыруда, район халкы арасында үзара аңлашучанлыкны ныгытуда уңышлар, нык сәламәтлек телибез. Һәм барыгызны да сайлау көнне тавыш бирү участокларына килеп, эшлекле һәм әйткән сүзендә тора торган кандидатыбызны яклавыбызны белдерергә чакырабыз.

**Хөрмәт белән чиркәү советы.**

## «Сездән ачык йөз булгач, бездән дә шулай булыр...»

***Татарстан Республикасы Дәүләт Советына депутатлыкка кандидат Ф.С.Сибагатуллин шул ук көнне тимер юлчылар клубында да сайлаучылар белән очрашты.***

Иң элек депутатлыкка кандидатның ышанычлысы Норлат станциясе начальнигы Л.Н.Газизуллина очрашуга килгән поселок халкын Ф.С.Сибагатуллинның тормыш юлы, эшчәнлеге белән таныштырды, Октябрь районы хакимият башлыгы вазифаларын башкаруына чамалы гына вакыт үтүгә карамастан, районның яшәешен уңай якка, халыкның социаль көнкүрешен яхшыртуга юнәлдерелгән чаралар үткәрүдә үзен күрсәтеп өлгерүен раслаучы мисаллар китерде һәм тимер юлчылар поселогында теркәлгән 3600 сайлаучыны кандидатны яклап тавыш бирергә чакырды.

- Тимер юл транспорты элек - электән ышанычлы транспорт булып кала бирә, шуңа да Норлатта тимер юл транспорты булуы белән мин икеләтә ундым,- дип башлады үзенең чыгышын Ф.С.Сибагатуллин һәм киләчәктә тимер юлчылар белән тыгыз элемтәдә, аңлашып, кыенлыкларны бергәләп җиңеп чыгу өчен аларга зур ышаныч багълавын белдерде. Шул ук вакытта мисалларда тимер юлчылар һәм гомумән район халкының күптәнге хәлиткеч проблемаларын тирәнтен аңлавын, алардан лаеклы рәвештә чыгу өчен барлык мөмкинлекләрне дә кулланырга әзер икәнлегенә ышандырды.

Залдагылар, үз чиратларында, аларга эчкерсез рухта мөрәҗәгать иткән депутатлыкка кандидатка исәпсез - хисапсыз проблемалары, гозерләре, сорауларын яудырдылар. Ә алар тирәннән килә һәм бүгенгесе көндә киң җәелгән: сайлаучыларның төп контингенты - пенсионерлар, инвалидларның өйләрендә су, җылылык җитми, канализация эшләми, поселокта бердәнбер мунча кыш буе ремонтта һәм башкалар... Кыскасы, тимер юлчылар тормышы, тимер юлчыларның төп җитәкчелегеннән еракта, ә район җитәкчелегеннән читтә кала бирде. Ф.С.Сибагатуллин сайлаучыларның гозерләрен аерым - аерым тыңлап игътибар үзәгенә алды һәм уңай хәл ителеренә ышандырды, соңында олыларны чиркәү ачылу тантанасына чакырды.

Депутатлыкка кандидат белән очрашуга килүчеләр аңа поселокта автобус маршруты ачуда ярдәм иткән өчен аерым рәхмәт әйттеләр һәм тимер юлчыларга карата якты йөз белән борылуыгыз куандырды безне,- дип хөрмәт белән җылы мөнәсәбәтләрен һәм тирән ышанычларын белдерделәр.

Җыелышта катнашучылар районның барлык сайлаучыларын Ф.С.Сибагатуллинны яклап тавыш бирергә чакырып мөрәҗәгать кабул иттеләр.

**Ф.ГАЛИМОВА.**

## *Сүздә генә түгел, эштә*

Без Октябрь административ - территориаль сайлау округының барлык сайлаучыларын 30 мартта, сүздә генә калмыйча конкрет эш күрсәтүче, аерым алганда, Норлатта Илья чиркәве төзелешен тизләткән хөрмәткә лаек Фатих Сәүбән улы Сибагатуллин кандидатурасын яклап тавыш бирергә чакырабыз. Ихлас рәхмәт Сезгә, Фатих Сәүбәнович, ходай Сезгә тазалык белән озын гомер бирсен.

**Школьная урамында яшәүчеләр исеменнән Н.КОЗЫРЬКОВА.**

## Хакимияткә хат килде

***Шушы көннәрдә район хакимияте башлыгы Ф.С.Сибагатуллин исеменә Татарстан Республикасы мәдәният Министрлыгыннан хат килде. Министр урынбасары М.Т.Низамиев имзасы куелган бу хатта түбәндәге юллар бар иде:***

«1997 елның 2 мартында Түбән Кама шәһәрендә «Чуваш сандугачы - 97» республика фестивалендә сезнең район вәкилләре дә катнаштылар. Оештыру комитеты һәм жюри сезнең үзешчәннәрнең әйбәт әзерлеген билгеләп үттеләр.

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы сезне «Родник» ансамбле (җитәкчесе С.Ефремова) һәм солитска И.Сафандеееваның конкурста лауреат, ә «Росинка» ансамбленең (җитәкчесе В.Бочкарев) дипломант исемнәрен яулаулары белән котлый. Сезгә районда һәм шәһәрдә чуваш мәдәниятын торгызу һәм үстерүгә сак, аңлап каравыгыз өчен рәхмәт белдерәбез».

## *Матбугат - 97*

## «Дуслык»ка льготалы язылу!

**Хөрмәтле укучыларыбыз!**

Без сезнең үз район газетагызны якын күреп, аны даими алдыруыгызга бик шатбыз. Заманаларның катлаулы һәм авыр булуына да карамастан, «Дуслык»ның тиражы тотрыклы тору, аңа ел дәвамында да язылучылар байтак булуы безне икеләтә куандыра. Бүген безнең газетаны шәһәрдә һәм авылларда ун меңгә якын гаиләдә алдыралар.

Һәм бүген, 1997 елның икенче яртысы өчен вакытлы матбугатка массовый төстә язылу кампаниясе башланырга торганда без Сезгә, газетабызның даими укучыларына мөрәҗәгать итәбез. 1 апрельдән элемтә бүлекләренә килеп, матбугат басмаларына язылганда без Сезнең иң беренче бланкларны «Дуслык»ка дип тутырачагыгызга шикләнмибез. Шунысын да әйтик, редакция, район элемтә узелы белән килешеп, район газетасына ярты елга язылу бәясен элеккечә, ягъни 23.400 сум көенә калдырды. Бу хакта үзегез күргән - белгәннәрнең моңарчы безнең газетаны алдырмаганнарына да җиткерерсез дип уйлыйбыз.

**Һәм, иң мөһиме!**

**Апрельнең 1еннән 10 сына кадәр «Дуслык» («Дружба», «Туслах») газеталарына льготалы бәягә, ягъни 16.200 сумга гына язылып калырга мөмкин. Район хакимияте башлыгы Ф.С.Сибагатуллин да бу инициативабызны хуплады.**

**Атнасына өч көн чыга торган матбугат органына язылуның шуннан да арзанрак бәясенең әле беркайда да булганы юк. Шулай булгач, нибары 16.200 сум акчагызны кызганмыйча, район газетасына язылып куйсагыз, ел ахырына кадәр райондагы хәлләр турында хәбәрдар булып торачагыгыз көн кебек ачык - анысына без ышандырабыз.**

**Дус булыйк, «Дуслык»лы булыйк!**

**Укучылар игътибарына!**

Газетабызның 2 нче битеннән **50 нче Октябрь административ - территориаль сайлау округыннан Татарстан Республикасы Дәүләт Советына депутатлыкка кандидат Фатих Сәүбән улы СИБАГАТУЛЛИННЫҢ САЙЛАУ АЛДЫ ПЛАТФОРМАСЫ белән таныша аласыз.**

## Чиркәү ачыла

**28 мартта җомга көнне Норлатта Илья чиркәве ачыла.**

Тантана иртәнге сәгать 10да башлана.

## *Җәйге вакытка күчәбез*

30 марттан 26 октябрьгә кадәр җәйге вакытка күчәбез. Русиядәге барлык сәгать телләре 30 мартта төнге сәгать 2 дә бер сәгатькә алга күчерелә.

## 30 март - Татарстан Дәүләт Советына депутат сайлау көне

### 50 нче Октябрь административ - территориаль сайлау округыннан Татарстан Республикасы Дәүләт Советына депутатлыкка кандидат Фатих Сәүбән улы СИБАГАТУЛЛИННЫҢ

# САЙЛАУ АЛДЫ ПЛАТФОРМАСЫ

**Мине 50 нче Октябрь административ - территориаль сайлау округыннан Татарстан Республикасы Дәүләт Советына депутатлыкка кандидат итеп күрсәткән «Норлат шикәр заводы» АҖ коллективына һәм мине яклаган, миңа ышаныч күрсәткән барлык коллективларга һәм хуҗалыкларга ихлас рәхмәтемне белдерәм.**

**Республика парламентында безнең район вәкиле булу, анда яшәүчеләрнең мәнфәгатьләрен чагылдыру минем өчен зур мәртәбә. Шул ук вакытта, кадерле райондашлар, Сез миңа йөкләгән зур җаваплылык та бу.**

**Һәм мин сайлаучыларым инде озакламый үз тормышларында уңай үзгәрешләрне тоя алсыннар өчен мөмкин кадәр күбрәк тырышлык, белем һәм тәҗрибәмне куячакмын.**

**Ә ул үзгәрешләр түбәндәге төп юнәлешләрдә ныклы эшләүгә бәйле булачагына иманым камил:**

- авылда реформалар үткәрүне тизләтү, ә ул ахыр чиктә продукция җитештерүне арттырырга, шуның белән бергә район халкының тормыш хәлен яхшыртырга, социаль - мәдәни багъланышлы, сәүдә объектлары, юллар төзүне һәм районны газлаштыру эшләрен алып барырга мөмкинлек бирәчәк;

- Октябрь районының барлык халкы мәнфәгатьләрендә шәһәр белән авыл арасында тагын да тыгызрак эшлекле хезмәттәшлек;

- кешеләрне гаять авыр шартларга куя торган түләмәүчелек һәм хезмәт хакын, пенсияләрне, пособиеләрне тоткарлау практикасы белән актив көрәш.

Безнең барыбызның да алдыбызда юл бер генә: сәяси һәм икътисадый тотрыклылык, милләтара татулык һәм тынычлык, социаль ориентлашкан һәм базар хуҗалыгы булдыру аркылы - төп максаты кеше, аның мәнфәгатьләре, уйлары һәм өметләре булган демократик цивилизация төзү.

Үз эшчәнлегемдә инвестиция активлыгын тайпылышсыз күтәрүгә ирешүне, икътисадны структур үзгәртеп коруларны дәвам итүне, агропромышленность комплексы эшчәнлеге өчен кулай икътисадый шартлар тудырып, халыкның тормыш хәлен тотрыклы итүгә һәм алга таба күтәрүгә юнәлдерелгән актив социаль сәясәт үткәрүне максат итәм. Болар һәммәсе, ахыр чиктә, районыбызның социаль тотрыклылыгы ныгуга китерәчәк.

Район икътисадын тотрыклыландыру өлкәсендә промышленность һәм авыл хуҗалыгында җитештерүне ныгытуга булышлык итүне, моның өчен авылга дәүләт ярдәменә, авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерүчеләр белән эшкәртү предприятиеләре арасында үзара файдалы партнерлык элемтәләре урнаштыруга, хуҗалык итүнең алдынгы тәҗрибәсен куллану нәтиҗәсендә авыл хезмәтчәненең абруен күтәрүгә, аның тормыш дәрәҗәсен сизелерлек яхшыртуга, кыр һәм ферма продукциясе җитештерү күләмнәрен үстерүгә ирешүне үземнең төп бурычларымнан дип саныйм.

**Бу уңайдан авыл хуҗалыгы производствосына тагын да кыюрак төстә реформалар үткәрергә:**

- хуҗалык эчендә исәп - хисап кертергә, эшләүчеләрнең матди кызыксынучанлыгын көчәйтергә;

- авылда ахыр чиктә продукция җитештерүне арттыруга китерердәй яңа структуралар һәм хезмәтне оештыру формалары кертергә;

- кырларның уңдырышлылыгын күтәрергә һәм яңа прогрессив технологияләрне кертергә;

- крестьян - фермер хуҗалыклары базасында үзенә үк терлек азыгы җитештерергә, үрчем, артым алырга, үз продукциясне эшкәртергә һәм урнаштырырга мөмкинлек бирәчәк кооператив һәм фермер хуҗалыклары төзергә кирәк.

**Икътисадый үзгәрешләр шартларында халыкның мөмкин кадәр тулырак мәшгульлегенә аерым игътибар бирүне үз бурычларымнан берсе дип саныйм.**

Моның өчен яшьләрнең һәм хатын - кызларның мәшгульлеге проблемасына аерым игътибар биргән хәлдә кадрларны яңадан әзерләү һәм яңа эш урыннары булдыру системасын төзергә кирәк.

Хезмәт кешесенә ул лаек булган тормыш дәрәҗәсе һәм социаль гарантияләрне саклау һәм ныгыту ягында торачакмын. Аз тәэмин ителгән социаль катлаулар - пенсионерлар, инвалидлар, ялгыз аналар, ятим балалар бүген моңарчы булмаган дәрәҗәдә яклауга мохтаҗ. Шуңа күрә пенсия һәм пособиеләрне үз вакытында биреп баруны җайга салырга кирәк дип саныйм. Бу эшне уңышлы алып бару өчен җитештерү өлкәсендә эшне җанландырырга кирәк.

**Социаль пландагы түбәндәге бурычларны иң алгы урынга куям:**

Бүген халыкның көнкүрешен яхшырту өчен газлаштыру иң әһәмиятле мәсьәләләрнең берсе булып тора. Бу юнәлештә зур эш эшләнде: газ үткәрүнең барлык эшләрен башкара торган «Татспецмонтаж» идарәсе, газ тутыру пункты, газ кулланучы җиһазларга хезмәт күрсәтү һәм ремонт белән шөгыльләнүче подразделениеләре булган «Норлатгаз» эксплуатация - җитештерү идарәсе төзелде. Газлаштыруны 2000 нче елга тәгәлләргә исәплибез.

Район үзәге халкын су белән тәэмин итү иң якын арада кичектергесез бурыч булып тора. Булган 5 скважинаны кабат сафка бастырабыз, Дала Мамыгыннан Норлатка суүткәргеч сузабыз. 1997 елның августыннан да калмыйча шәһәргә артезиан суы киләчәк.

Районны электр белән тәэмин итүнең ышанычлылыгын яхшырту максатларында подстанцияләрне һәм электр үткәргеч линияләрне реконструкцияләү чаралары күреләчәк. Массакүләм мәгълүмат чараларының матди - техник базасын ныгыту, җирле телевидение төзү эше планлаштырылган.

Үз эшчәнлегемдә районда телефон элемтәсен җайга салырга һәм Норлат белән Татарстан башкаласы арасында регуляр һава элемтәсе тәэмин итәргә тырышачакмын.

Юллар һәм күперләр төзү, хуҗалык эчендәге юлларны асфальтлау мәсьәләләре дә игътибар үзәгендә булачак.

Җинаятьчелеккә каршы көрәшне көчәйтү өчен законнар чыгару процессын үстерү ягында торам. Законлылыкны ныгыту, гражданнарның иминлеген һәм аларның милкен саклауны көчәйтү юнәлешендәге тәкъдимнәрне яклыйм.

**Социаль - мәдәни багъланышлы объектларның бүгенге торышы райондагы төп һәм көнүзәк мәсьәләләрнең берсе дип саныйм.**

Шәһәрдәге бердәнбер кинотеатрны тиз арада үзгәртеп корырга, анда никахлашу залы һәм яшьләр кафесы ачарга кирәк.

Кыска срокларда Норлатта картлар йорты, район үзәк шифаханәсендә стационар корпуслар, урта мәктәп төзү бурычы тора.

Мәдәният, сәүдә, сәламәтлек саклау, мәгариф проблемалары да читкә куелмаячак, чөнки кешеләрнең рухи һәм физик халәте күп яклап шушы өлкәләрнең эшчәнлегенә бәйле.

**Мин алга таба да район территориясендә яшәүче халыкның милли мәнфәгатьләре тигезлеген бер дәрәҗәдә гарантияләргә ниятлим.**

Районыбыз халыкларының туган телләрен кабат торгызу проблемасын хәл итүне тизләтергә, аларның мәгърифәтен һәм мәдәниятен үстерергә кирәк дип саныйм.

**Кешелекнең сәламәтлек, матди муллык, гарантияләнгән эш, гаилә бөтенлеге, тыныч картлык, бәхетле балачак кебек иң гади кыйммәтләрен тәэмин итү һәм гарантияләүне үземнең төп максатым дип саныйм.**

**Шул чакта гына минем сайлаучылар алдындагы бурычым үтәлгән булачак.**

## «Ачык хатлар көне»ннән

# СОРАУЛАР, ҮТЕНЕЧЛӘР... ҺӘМ ҖАВАПЛАР

***Мәгълүм булганча, 14 мартта район мәдәнияті йортында Татарстан Республикасы Дәүләт Советына депутатлыкка кандидат, район хакимияте башлыгы Ф.С.Сибагатуллинның шәһәр халкы белән очрашуында «Ачык хат көне» дә үткәрелгән иде. Сайлаучылардан ул көнне телдән дә, язма рәвештә дә сораулар күп булды. Һәм менә шуларның берничәсенә җавапны без газета аша бирергә булдык.***

Шәһәрнең кайбер почмакларында телефон кертү проблемасы һаман да актуаль булып кала бирә. Инвалидлар һәм ветераннарны бу мәсьәлә бигрәк тә борчый. Лобачевский урамында яшәүчеләр һәм Лихачев урамында яшәүче хезмәт ветераны, пенсионер З.М.Ивановадан җибәрелгән хатларда да шул проблема кузгатыла. **«Без яңа телефон станциясе төзегәндә 3000 сум акча түләгән идек, ул чакта аз сумма түгел иде бу. Ләкин шуңа карамастан, һаман да телефон кертелми,»**- диләр олылар.

Ә З.Ивановаңың гаризасы 1981 елдан бирле элемтә бүлеге бухгалтериясендә ята икән. «Инде льготалы бәя белән кертеп булырмы?»- дип кызыксына ул. Ләкин Норлат - Октябрь район элемтә узелы начальнигы Р.Ә.Җиһаншин җавабыннан аңлашылганча, аның үтенече канәгатьләндерелми, чөнки Лихачев урамы кергән микрорайонда линия корылмалары булмаганга бүгенге көндә аның өенә телефон кертү өчен техник мөмкинлек юк. Ә Лобачевский урамында яшәүчеләргә аларның җавабы җылырак:

«... Тимер юлчылар поселогында линия элемтә корылмалары төзелеп беткәч, Лобачевский урамындагы заемчыларга телефон кую мәсьәләсе 1997 елда хәл ителәчәк».

Шәһәрнең торак - коммуналь хуҗалыгына берничә сорау юлланган:

**«Шәһәргә чиста су җитми, киләчәктә бу мәсьәлә ничек хәл ителер?»**

«Бүгенге көндә МППда тәүлегенә 3200 кубик метр су үткәрә торган су чистарту корылмасы бар. Хәзерге вакытта аның куәтен тагын 3000 кубик метрга арттыру буенча киңәйтү эшләре алып барыла, шул ук вакытта Дала Мамыгы - Норлат суүткәргече дә торгызыла. Каравыл Тавы янында тәүлегенә 20000 кубик метр сыешлы Шандор плотинасы төзелеше башланды».

**«Сукбай этләргә каршы көрәш алып барыламы?»**

«Әйе, 1996 елда 230 эт атылды, ә 1997 елда 140. Ату дәвам итә».

**«Хрущевка»ларда яшәүчеләр өчен фатирга түләүнең тәртибе ничек? Без бу йортта 30 елдан артык яшибез. Түләү дә яңа йортлардагы кебек булмаска тиештер бит»**- дип сорыйлар Советская урамының 92 нче йортында яшәүчеләр. «Әйе, бу йортта яшәүчеләр фатирга йортның тузганлыгын исәпкә алып түлиләр»,- дип җавап бирә МПП җитәкчелеге.

**«Төзүчеләр урамындагы йортлар кайчан газлаштырылачак?»**- дигән сорауга халык депутатларының район Советы рәисе урынбасары Е.К.Савинов түбәндәге җавапны бирде: Төзүчеләр урамы районның 1997 елгы газлаштыру планына кертелде һәм аның нигезендә эш башкарылырга тиеш».

**Бер пенсионер хатын - кыз (исемен атамаган) пенсияләрне яңадан хисаплауның кайсы вакытта буласын һәм минималь һәм максималь пенсияләрнең күләме турында сорый.** Ана район социаль тәэминат бүлегеннән бүгенге көндә индивидуаль коэфициент нигезендә пенсияләрне яңадан хисаплауга әзерлек эшләре баруы турында белдерәләр. «Пенсияләр «Дәүләт пенсияләрен исәпләп чыгару һәм арттыру турында»гы Федераль Законның I проекты маддәсе нигезендә хисапланачак. Пенсия күләме пенсионерның индивидуаль коэфициенты буенча халык хуҗалыгында алдагы кварталга эшләп алган уртача айлык хезмәт хакыннан чыгып исәпләнә. Хәзерге вакытта Федераль Закон проекты хөкүмәт каравында.

Бүгенге көндә минималь пенсия (яшь буенча) - хезмәт стажына карап 69575тән 83490 сумга кадәр, максималь (шулай ук яшь буенча) - пенсионерның эш хакы һәм стажына бәйле рәвештә 208755 тән 250470 сумга кадәр җитә»- диелә җавапта.

Кайбер шәхси характердагы сорауларга да җаваплар бар биредә.

М.Гафурова: **«Шикәр заводында яңа төзелгән йортта фатирлар бүленгән, дип әйттеләр, безгә фатир бирелми микәнни инде?,**- дип сорый. Ана шикәр заводы директоры А.К.Савинов түбәндәге җавапны бирә: «Н.Г.Гафуров кранчы булып эшли. ... 1992 елдан торак шартларын яхшырту чиратында 81 нче исәпләнә. Төзелә торган 5 катлы йорт файдаланута тапшырылмаган әле, шуңа да сатылмады һәм бүленмәде дә. Фатирлар чират нигезендә, 2 нче, 3 нче, 4 нче льготалы исемлекләрне һәм коллектив килешүдә язылган положенийеләрне исәпкә алып бүленәчәк».

## Районыбызның хезмәт коллективларында

# КУЛЛАРЫННАН КИЛМӘГӘН ЭШ ЮК

***Норлатка бер килүендә нефтьчеләрнең яңа профилакториен караган «Татнефть» АҖ генераль директоры Р.Г.Галиев тә шаккаткан иде бу бинага.***

***- Күп җирләрдә булып, әллә нинди ял йортларын күрергә туры килгәне бар. Әмма мондагысы - искиткеч, Швейцариядәгедән бер дә ким түгел,- диде ул тел шартлатып.***

Ә безнең өчен оҗмах та оҗмах инде ул. Бина үзе, аның зур зәвык белән җиһазланган эчке ягы - барысы да гаҗәпләнерлек. - Хәер, биналар һәм корылмаларга капиталь ремонт үткәрү цехы (ЦКРЗС) осталары эшкә алынса, аны аннан - моннан гына башкарып, ярты юлда ташлый торганнар түгел инде. Соңгы елларда исә Европа стандарты дәрәҗәсенә күчүгә йөз тотылганда таләпләр тагын да үсте, шуның нәтиҗәсендә эшнең сыйфаты да күзгә күренеп яхшырды. Әнә «Огонёк» кибетендә нинди зур реконструкция эшләре башладылар. Ул кибетнең даими сатып алучылары да танымаслык булып үзгәрде бит. Укыту - курс комбинаты да цех эшчеләре кулы тиюгә үк башка кыяфәт алды. Ә НГДУның сөт - май комбинаты? Биредә дә төзелеш эшләрен ЦКРЗС алып барган иде бит һәм испан технологияле заводның йөзе дә бездәге бер генә производствоныкы белән чагыштырмалы түгел. Әле менә җәй заводның мәйданын киңәйтүне дә НГДУ әлеге цехка йөкләмәкче була. «Яшьлек» кафесын да зур үзгәрешләр көтә. Норлат яшьләре горурлыгы итмәкче булалар аны да.

Күпләр Әхмәт авылының НГДУга ярдәмче хуҗалык итеп тапшырылган көннәрен хәтерлиләр булыр. Терлекчелек, шулай ук социаль - мәдәни объектларның барысы да ярым җимерек иде. Биредә объектларның барысын да диярлек ЦКРЗС корды, ремонтлады. Хәзер исә авыл эчендәге үзгәрешләргә таң калырлык. - НГДУ эшчәнлегендә әлеге цехның өлеше әйтеп бетергесез зур,- ди бу уңайдан идарә начальнигы М.М.Хуҗин - бездә алар өчен эш фронтының һичкайчан беткәне юк.

Анысы хак. Ни өчен дигәндә, шәһәребездәге иң эре предприятие саналган әлеге идарәнең бер генә объектында да эш башкармый калмыйлар алар: төзиләр дә, ремонтлыйлар да, бизиләр дә. Цехның идарә составында булуы акча күчерүгә бәйле проблемалар да тудырмый. Дөрес, элек материаллар НГДУ аркылы турыдан - туры поставкалар буенча кайтарылса, хәзерге заманда аларны эзләп аласы. Шулай булса да, сайлап алу мөмкинлегенең киң булуы белән отышлы. Ә материал булганда, цехның эшенә тоткарлык тудырырлык башка сәбәпләр юк. Бу җәһәттән, цехта төзү - ремонт эшләре алып бару өчен барлык һөнәр ияләре дә бар. Ташчылар, балта осталары, столярлар, плитә белән йөзләүчеләр, электрчылар, сантехниклар, хәтта калайчылар да эшли. Ун кешелек эретеп ябыштыру, 20 кешелек штукатур - бизәүчеләр бригадасы да зур көч.

Шәһәрдә, һичкайда булмаган художество цехы да бар биредә. Искиткеч әйбәт белгечләр эшли монда. Алда телгә алынган профилакторий дизайнын булдыру өчен алар тырыштылар бит. Гомумән, соңгы елларда әлеге цех төзегән, ремонтлаган объектларның матурлыгы, зәвыклыгы иң элек менә бу төркем өлешенә туры килә. Идарә горурлыгы булып торырлык итеп, югары зәвык белән җиһазланасы объектларда да подрядчы эзләмичә эшне һич икеләнүсез аларга тапшыралар. Хәер, цех өчен яннан кеше яллап эшләтү бөтенләй ят нәрсә. Хәзергә бары мәрмәр белән эшләү өчен генә читтән кеше ялларга мәҗбүрләр. Әмма якын киләчәктә бу эшне дә үзләштерергә исәплиләр. Ә биредә үз дигәннәренә ирешмичә калмыйлар. Әнә элегрәк ремонт, төзелеш өчен кирәкле барлык агач эшләнмәләрен кайдан мөмкин шуннан сатып алалар иде. Ә аларның кыйммәтлелеге... Хәзер столярлык цехы каршында киптерү җайланмасы да куйгач бер дигән тәрәзә рамнарын, ишекләр һәм башкаларны үзләрендә үк ясый башладылар. Аларның үзкыйммәте дә сатып алганнарыныкыннан икеләтә ким чыга.

- Замана кыенлыгы безне һәрнәрсәгә икенче төрле карарга мәҗбүр итә,- ди бу уңайдан цех начальнигы Ш.Г.Яһудин. - Материалларны сак тотып, даими эзләнеп, югары сыйфатлы эшләү генә бүгенге конкуренция заманында өске «агымда» барырга ярдәм итә.

Бу уңайдан ул икенче бер мисал да китерә. Цех каршында зур ук теплица бар. Заманында помидор да, кыяр да үстерделәр биредә кызлар. Соңгы елларда нигездә суган, аш тәмләткечләр һәм чәчәкләр белән эш итәләр. Теплица -үзен - үзе акламый: электр энергиясе бик күп сарыф ителә биредә. Әмма цех җитәкчелеге аны икенче төрле нәрсәгә хезмәт иттерү турында уйлап та карамый: чыгымнарын башка участоклар исәбенә каплап бара.

- Төрле тантаналар, зур чаралар өчен чәчәге - башкасы кирәк булганда, халыкка аларны килеп сатып алу мөмкинлеге булу - үзе бер уңайлык бит,- ди бу уңайдан Шамил Гәбделхәевич, аннары берничә хатын - кызның булса да эш урыны да саклана бит әле...

Әйе, соңгы вакытта шәһәрдә кискен «сикереш» ясалган эшсезлек тә игътибарга алына биредә. Соңгы елларда монда яңа эш урыннары булдыру бәрабәренә бер генә кеше дә «кыскартылмаган». Моңа цехта эшләүчеләрнең шәһәрдәге барлык төзелеш оешмалары көнләшерлек хезмәт хакы алуларын да өстәсәң...

- Эшләвебезгә карата инде анысы,- диде төзүчеләрнең берсе,- алны - ялны белмибез бит без кайчак...

Хәер, моны исбатлап торасы да юк. Башкарылган эшләре күз алдында бит.

**Р.ГИНЯЕВА.**



# Төгәллек хас аңа

Була шундый кешеләр: алар эшкә урнашуга ук коллектив тормышы белән яши, эшнең үзәгендә кайный башлыйлар. Илгиз дә шундый: «Норлат - Октябрь ит комбинаты» агрофирмасына эшкә килүенә озак вакыт үтмәсә дә иптәшләре, гомумән, коллектив белән дә яхшы мөгамәләдә, үз вазифасын да бик әйбәт белә.

И.Нотфуллин «КамАЗ» автомашинасын йөртә. Ул агрофирманы чимал белән тәэмин итүчеләрнең берсе. Иртән иртүк егет район хуҗалыкларының тегесе яки бусына барып, терлек төяп кайта. Кайчак көн дәвамында берничә хуҗалыкта булырга туры килә аңа. Илгиз эшендә һәрчак төгәл.

**Н.АЗИЗОВ фотосы.**

## Халыкка уңай булсынга

# Аптека пунктына шатлар

«Сельхозтехника» микрорайонында яшәүче халык акционерлык җәмгыять медпунктында Самара өлкәсенең Чаллы Башы үзәк аптекасы филиалы буларак пункт ачылуына сөенеп бетә алмыйлар: ни дисәң дә, үзәк аптека якын түгел, ә өлкән кешеләр өчен аның кыска юлы да озын булып тоела.

Пунктта дарулар ассортименты да киң, бәйләү средстволары һәм башкасы да бар. Пункт мөдире Гөлфия Рәшитовна Шәһидуллина бирегә мөрәҗәгать иткән һәр кешегә игътибарлы: авыруларга даруларны сайларга булыша, ә инде алар булмаганда, заказлар да алып кала.

Монардан тыш, халык бирегә уколга да йөри. Шәфкать туташы Гөлфия исә аларның кайда яшәүләренә карамастан, берсен дә кире бормый: процедураларны җиңел кулдан зур җитезлек белән башкара.

Медпункт бинасы үзе җылы, чиста. Ул күргәзмә материалга да бай. Сәламәт яшәү рәвешен пропагандалаган, төрле авыруларны профилактикалау буенча чыгарылган махсус бюллетеньнәр, листовкалар янында тукталып, алар белән танышучыларны да еш очратырга мөмкин.

# Мунча - саунада бик рәхәт!

Мастерскойлар территориясендә урнашкан мунча - саунада халык һәрчак күп була. Пәнҗешәмбе һәм шимбә көннәре биредә хатын - кызлар, чәршәмбе, җомга, якшәмбе көннәрне исә мунчага ир - атлар хуҗа. Юынучылар арасында «Сельхозтехника» микрорайонында яшәүчеләр дә, башка яклардан да халыклар теләп йөри. Шулай булмый ни: өч мең сумыңны түлисең дә, телисең саунага, телисең пар бүлмәсенә керәсең. Душ та эшли, суга исә һичкайчан өзеклек булмый. Чыккач әле чәй дә тәкъдим итәләр. Ә биредәге чисталык - сокланырлык. Мунча хуҗасы Альбина Александровна Ефимова аны карап - чисталап торырга да өлгерә, акчаны да үзе җыя, чәйне дә хәзерли.

## Спорт спорт спорт

# Норлатка көрәшчеләр җыела

**Быелның 28 - 30 мартында балалар һәм яшүсмерләрне физик хәзерләү буенча спорт клубы (ДЮКФП) базасында спорт мәктәпләре һәм клубы яшь спортчылары катнашында милли көрәш буенча республика ярышлары үтәчәк. Анда 1980 нче елгы һәм аннан яшьрәк көрәшчеләр катнашачак.**

**Норлатка әлеге чарада катнашу өчен республикабызның 15ләп эре шәһәреннән яшь көрәшчеләр килүе көтелә.**

***

Узган җомгада ДЮКФПда республика ярышларында катнашачак яшүсмерләрне сайлап алу буенча район ярышлары үтте. Анда яшь көрәшчеләре белән дан тоткан Чулпан, Югары Норлат, Киекле, Түбән Норлат урта мәктәпләреннән һәм клубның үзендә шөгыльләнүчеләр катнашты.

# Афәрин, киеклелеләр

Гер спорты район яшүсмерләре арасында киң таралган спорт төре дип әйтеп булмаса да, аның белән чын - чынлап мавыгып шөгыльләнүчеләр аз түгел икән. Узган якшәмбедә балалар һәм яшүсмерләрне физик хәзерләү буенча спорт мәктәбендә үткән ярышлар да шуны раслады. Анда Киекле урта мәктәбе егетләренең (тренерлары Фәрит Сәләхетдинов) нәтиҗәләре аеруча яхшы булды. 70 килограммга кадәрле үлчәүдә Илшат Гыйләҗетдинов ике кулындагы 16шар килограммлы герләрне 90 (!) тапкыр югарыга чөйгәч, ярышта катнашучылар да, тамашачылар да «аһ» иттеләр. Шул ук үлчәү категориясендә икенче урынны яулаган Киекле авылы егете Рәдиф Митаковның да нәтиҗәләре әйбәт булды.

70 килограммнан авырлар арасында да әлеге мәктәп укучылары лидерлык итте. Беренчелекне яулаган Зөлфәт Сөнгатуллин герләрне 65 тапкыр күтәрде.

Җинел үлчәү категорияле спортчылар арасында да шул ук авыл егетләре җиңүче булды. Илшат Сафин герләрне 40 тапкыр һавага чөйде. Афәрин, киеклелеләр.

**Р.МИНАПОВА.**




## Вакытлы матбугатка язылу бара

# 1 апрельгә кадәр генә

Татарстан Республикасы Элемтә министрлыгыннан хәбәр итүләренчә, 1 апрельдән 1997 елның икенче яртыеллыгына газета - журналларга язылу башлана. Билгеле, яңа, күтәренке бәяләрдән.

Элемтәчеләр белән бергәләп фикер алышканнан соң, «Ватаным Татарстан» редакциясе үз газетасына язучылар өчен ташлама, льгота ясарга булды. Хикмәт шунда: икенче яртыеллыкка иске бәяләр белән «Ватаным Татарстан» газетасына инде март аенда ук язылырга мөмкин. Димәк, без бүген үк 1997 елның икенче яртыеллыгына «Ватаным Татарстан» газетасына иске бәядән языла аласыз. 54123 индексы буенча гомуми язылу бәясе 42 мең 600 сум, 54211 индексы буенча (пенсионерлар өчен) 40 мең 800 сум. Кабат исегезгә төшерәбез: бу бәяләр 1 апрельгә кадәр генә сакланачак.

Димәк, газетабызның хөрмәтле укучыларына бүген үк элемтә бүлекләренә ашыгырга гына кала.

**И.ДИНДАРОВ, газетаның үз хәбәрчесе.**

## Котлыйбыз!

Сөекле тормыш иптәшем, кадерле әтиебез, зур әтиебез **Нуриҗан Исхак улы Азизовны** 60 яшьлек юбилее белән кайнар котлыйбыз.



Юбилееңбелән котлап, әткәй,
Без телибез сиңа иң элек
Ныклы саулык, бәхет, озын гомер,
Бөтен гаиләбезгә иминлек.
Авырлыклар кайты, авырулар
Урап үтсен безнең өй эчен.
Дөньяң күге һәрчак аяз булсын
Һәм уң килеп торсын һәр эшең.

**Тормыш иптәше, уллары-киленнәре, кызы - кияве һәм оныклары.**

*Норлатта яшәүче кадерле* ***әтиебез Радик һәм әниебез Исламия Сибгатуллиннарның*** *27 мартта бергә торуларына 25 ел тула. Без аларны олы юбилейлары белән чын күңелдән котлыйбыз, сәламәтлек, бәхет һәм бергә тигез гомер кичерүләрен телибез.*



*Бүләгебез - саф теләкләр*
*Сезгә, әти - әниебез.*
*Изгелектә, игелектә,*
*Иминлектә гомер итегез.*
*Әти - әни, яшәгез сез,*
*Авыруларны белмичә.*
*Тормыш юлларыгыз үтсен*
*Кайгы җиле тимичә.*

***Иң изге теләкләр белән балаларыгыз: Алсу, Нурисә, Зифа, Адик, кияүләрегез Рафик, Наил.***

## Белдерүләр


***Идел Буе региональ наркология үзәге***

***Табиб М.Б.Багрянцев.***

***Алкогольгә бәйлелектән һәм тәмәке тартудан бер сеанста кодлаштыру.***

***Бездә генә!***

**Тулы анонимлык. Индивидуаль якын килү. Дәвалау барышында пациентның туганнарына да катнашырга рөхсәт ителә. Белешмә бирелә. Консультация, әңгәмә, кодлаштырудан соң күзәтү һәм ярдәм - бушлай!**

**Язылу һәм әңгәмә дәвалау көнне, җомга көнне, 28 мартта көндезге сәгать 2дә район мәдәният йорты бинасында уздырыла.**

РФ сәламәтлек саклау министрлыгыннан 1995 елның 16 гыйнварында бирелгән № 00164 - 30 лицензия.


### Сатабыз

**Бер бүлмәле фатир.** Тел.: 5 - 17 - 80.

***

**1996 елгы «Ока» машинасы**. Тел.: 5 - 18 - 01.

***

**Островский ур., 3б адресы буенча кирпеч йорт (8[illegible] квадрат метрлы, үзәктән җылытыла, суы, мунчасы, базы, таштан сарае, гаражы, коесы, 12 сутый бакчасы бар).**

***

**1988 елгы ВАЗ - 2105**. Тел.: 2 - 26 - 10.

***

**1996 елның маенда чыккан, гранат төсендәге, 06 двигательле, 2500 км. йөргән ВАЗ - 21074не ашыгыч төстә.** Тел.: 2 - 24 - 90 (кичке 4кә кадәр) яки 65 - 3 - 53 (кичке 5тән соң).

***

**9 х 9 метрлы җыелма йортлар. Китереп бирү мөмкинлеге бар.** Адрес: Яр Чаллы шәһәре, Орловка поселогы, Центральная ур., 67, тел.: 54 - 16 - 34. 1740 номерлы таныклык.

***

**Әйбәт хәлдәге ВАЗ - 21013**. Чулпанда тел.: 3 - 83 - 90.

***

**Суворов ур., 99 адреслы йорт.** Тел.: 2 - 27 - 49 (сәгать 8дән кичке 5кә кадәр).

***

**6 х 12 метрлы профнастил.**
Адрес: Завод тыкрыгы, 9 - 7.

***

**«Алмалык»та бакча йортлы дача участогы**.
Адрес: Совет ур., 189 - 21.

***

**46 - 48 үлчәмдәге төрле модельле кәшемир пәлтә.** Адрес: Ленин ур., 30 - 22, тел.: 2 - 24 - 83.

### Алмаштырабыз

**Нефтьчеләр урамы, 14 - 27 адресы буенча 3 бүлмәле фатирны - 2 һәм 1 бүлмәлеләргә.** Дружба ур., 8 - 1 адресы буенча мөрәҗәгать итәргә.

***

**Тельман тыкрыгы, 5 адресы буенча участогы белән йортны - ике бүлмәле фатирга. Башка вариантлар да мөмкин.**

***

**Норлаттагы шәхси йортны (Декабристлар ур., 6) - Яр Чаллыда фатирга.** Яр Чаллыда тел.: 54 - 21 - 38.

### Сатабыз яки алмаштырабыз

**Чаллы Башындагы 2 бүлмәле фатир ашыгыч төстә сатыла яки Норлаттагыга алмаштырыла.** Чаллы Башында адрес: СХТО ур., 5 - 11, Норлатта тел.: 5 - 18 - 08.

***

**1994 елгы ГАЗ - 53 вахта автобусы сатыла яки КамАЗга алмаштырыла. Шулай ук «Полюс - 10» суыткычы, «Урал» мотоциклына паспорты белән яңа двигатель, кабер ташлары өчен 3 комплект мәрмәр плитәләр сатыла.** Тел.: 2 - 15 - 88.

### Табучы юкмы?

**Фәрит Вазыйх улы Әхмәтшин исеменә бирелгән 790845 номерлы таныклык, шулай ук документлар (лицензия, техник талон, паспорт һәм кисәтү талоны) югалды.** Табучының бүләк бәрабәренә Совет ур., 79 - 9 адресы буенча китереп бирүен үтенеп сорыйбыз.

## Сәламәт булыгыз!

# Алоэ гөленең файдасы



Сезнең өегездә алоэ гөле үсәме? Үсәдер, мөгаен. Чөнки аның күп авырулардан файдалы үсемлек икәнен һәркем беләдер. Бүгенге медицина алоэны төрле дарулар ясау өчен файдалана. Әмма ул даруларны сатып алу өчен аптекага йөгермәскә дә була.

Өй шартларында алоэ согыннан файдалану өчен иң элек гөлнең түбәнге һәм урта өлешендәге нык, таза яфракларын өзеп алыйк. Юып киптерик. Аннары 12 көнгә 4 - 8 градуслы салкын, караңгы урынга куйыйк. Мондый шартларда яфраклардагы бөтен яшәү чыганагы үлә. Әмма гаҗәеп бер хәл күзәтелә: үсемлектәге күзәнәкләр яшәү өчен бөтен көчен туплаган арада үзенә бер төрле матдә хасил була. Галимнәр аны «биоген стимуляторы» дип атыйлар. Ул үлеп бара торган күзәнәкләрне терелтә, яшәү көче бирә. Менә шундый ысул белән табылган сок та кеше организмы өчен биостимулятор булып тора. Кеше организмына килеп керү белән ул беренче чиратта авыру урынга тәэсир итә, тукымадагы матдәләр алмашуны көчәйтә, авыруларга каршы тору көчен арттыра, тизрәк савыгырга булыша. Бигрәк тә ул тире авыруларын (дерматоз, экзема, тимерәү) дәвалау өчен файдалы.

Әгәр биостимулятор согын эвкалипт һәм кастор мае (2:2:1) белән кушсаң, тән тиресе пешкәндә бик яхшы дәвалау чарасы була.

Ниндидер авырудан соң организм бик нык хәлсезләнгәндә яки үпкә туберкулезы булганда, алоэ согын эчү файдалы. Менә мондый состав күпләргә билгеле: 150 грамм биостимулятор булырлык сок әзерләү өчен 250 грамм бал, 250 грамм «Кагор» шәрабын бергә кушалар да көнгә өч тапкыр ашарга ярты сәгать кала берәр аш кашыгы эчәләр.

Үпкә авырулы кешеләргә менә мондый составта эшләнгән дару файдалы: 150 грамм алоэ согы, 100 грамм атланмай, дуңгызның эчке мае яки каз мае, 100 грамм бал һәм какао порошогын бергә кушып, 1 стакан кайнар сөткә 1 аш кашыгы шул катнашманы салырга, көнгә 2 - 3 тапкыр эчәргә. Тәндә җәрәхәтләр булганда яңа гына өзеп алган алоэ яфрагын ябарга киңәш ителә.

Салкын тигәндә, тамак һәм тын юллары ялкынсынып торганда алоэ согы белән тамакны чайкау бик әйбәт нәтиҗә бирә. Моның өчен биостимулятор булырлык яфракларны иттарттыргыч аша үткәреп, шуңа 5 өлеш күләмендә су кушыла һәм 1 сәгать дәвамында тондырыла. Аннары шул масса җылытылып, 2 - 3 минут кайнатыла һәм марля аша сөзелә. Әгәр бу төнәтмәне берьюлы файдаланып бетермәсәгез, икенче юлы кулланганда тагын бер кат кайнатып алырга кирәк.

Ә менә бусы сәламәтлекләре начар булган балаларга эчерә торган катнашма (балаларга 6 яшьтән башлап эчертергә була): 100 грамм алоэ согы, 50 данә кузы чикләвеге төше, 300 грамм бал, 3 - 4 лимон согын кушып, берәр чәй калагы (9 - 10 яшьлекләргә десерт кашык) белән. Аны ашарга ярты сәгать кала көнгә 3 тапкыр эчәргә кирәк.

Алоэ согы тән җәрәхәтләрен төзәтә дип әйткән идек инде. Әмма ул әле косметикада да бик әйбәт дару икән. Тәндәге сызлавыкларны, бит тиресе бик майлы булса, аның маен бетерә, тән тиресен картаюдан, ләшперәеп төшүдән саклый. Тик монда, әлбәттә, сокны куллана белү сорала. Әйтик биттәге майны киметү өчен биостимулятор итеп әзерләнгән яфракларның каралып киткән урыннарын алып ташлап, тәлинкәдә төябез яки иттарттыргыч аша чыгарып, ике кат марля аша сыгабыз. Биткә бары тик яңа әзерләнгән сокны гына сөртергә ярый. Әгәр ул сокны озаграк сакларга теләсәгез, 8 өлеш сокка 2 өлеш чиста медицина спирты кушырга кирәк.

Җыерчыкларны бетерү өчен атнага ике тапкыр 10ар минут дәвамында шул сокка манчылган мамык ябып торырга кирәк. Мондый ысул биттәге сызлавыкларны бетерү өчен дә бик әйбәт була.

Әгәр менә шушы гади генә профилактик чараларны куллансагыз, бит һәм муен тирегез яшәреп киткәндәй булыр, матур һәм шома күренер.

**ТАТЬЯНА ЮРКОВА, биология фәннәре кандидаты. («Шәһри Казан»нан).**


БАШ МӨХӘРРИР **Р.Ф.ҖАМАЛИЕВ.**

МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА**

**Учредительләр: Октябрь район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.**

**"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.**

**Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Норлат шәһәре, Карл Маркс урамы, 19.**

**Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, җаваплы сәркәтип - 2-18-67, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия, реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.**

***Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.***

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2083 данә.